ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.07.2019**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1374**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 июнендәге «Зеленодольск шәһәр пляжында су коенуны тыю турында» 1272 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Су кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131 – ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск шәһәр пляжы районында сайлап алынган Идел елгасыннан алынган су пробасының санитар-химик һәм микробиологик күрсәткечләр буенча «Җир өсте суларын саклауга карата гигиеник таләпләр» СанПиН 2.1.5.1315-03, «Хуҗалык-эчәр суларының һәм мәдәни-көнкүреш судан файдалану объектлары суында химик матдәләрнең иң чик концентрациясе (ПДК)» ГН 2.1.5.1315-03 таләпләренә туры килүе турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматларын исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 елның 04 июленнән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 17 июнендәге «Зеленодольск шәһәр пляжында су коенуны тыю турында» 1272 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. «Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» МБУ җитәкчесе А.О. Антоновка су коенуны тыю турында кисәтү аншлагларын сүтү эшен оештырырга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), «Зеленодольская правда» һәм «Яшен Үзән» басмаларында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников